| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.09.2018 Балык Бистәсе штп. № 230пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган “2015 – 2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру” муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы тору системасын камилләштерү максатларында һәм Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 29 июнендәге “2018 – 2020 елларга коррупциягә каршы тору Милли планы турында”гы 378 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 20 гыйнварындагы 38пи номерлы карары белән расланган “2015 – 2020 елларга Балык Бистәсе муниципаль районында коррупциягә каршы сәясәтне тормышка ашыру” муниципаль программасына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 31 маендагы 80пи, 2016 елның 27 сентябрендәге 157пи номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлектәге бүлек белән тулыландырырга:

**“11 бурыч. Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 29 июнендәге “2018 – 2020 елларга коррупциягә каршы тору  Милли планы турында”гы 378 номерлы Указында каралган чараларны тормышка ашыру.**

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 11.1.Мәнфәгатьләр низагын булдырмый калу һәм җайга салуга кагылышлы Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы закон таләпләренең муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштыручы затлар тарафыннан үтәлүе өчен контрольне гамәлгә ашыру, билгеләнгән таләпләрне үтәмәүче затларны дисциплинар җаваплылыкка тарту | Вазыйфаи затлар, җирле үзидарә органнарында коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы затлар (килештерү буенча) | Квартал саен | Мәнфәгатьләр низагын булдырмый калу һәм җайга салу турында таләпләрне үтәүне тикшерү/үткәрелгән анализлар саны муниципаль хезмәткәрләрнең гомуми саныннан; мәнфәгатьләр низагын булдырмый калу һәм җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән өчен дисциплинар җаваплылыкка тартылганнарның саны мәнфәгатьләр низагы белән бәйле хокук бозуларны кылган муниципаль хезмәткәрләр саныннан | | | | | 50% | 100% | 100% | - | - | - | - | - | - |
| 11.2. Кадрлар эшенең, аның муниципаль | Вазыйфаи затлар, җирле үзидарә | Ярты елга бер мәртәбә | Муниципаль хезмәткә беренче тапкыр керешүче | | | | | 90% | 90% | 90% | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштыручы затларның личное делоларын алып баруга, шул исәптән, булуы мөмкин булган мәнфәгатьләр низагын ачыклау максатларында, күрсәтелгән вазыйфаларга билгеләгәндә һәм андый хезмәткә кергәндә тапшырылган анкеталардагы мәгълүматларны актуальләштерү өчен контрольгә кагылышлы өлешенең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча чаралар күрү | органнарында коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы затлар (килештерү буенча) | | һәм махсуслаштырылган укулар узган хезмәткәрләрнең саны муниципаль хезмәткә беренче тапкыр керешүчеләрнең гомуми санынннан (90% тан ким түгел) | | | | | | | | | | | | | |
| 11.3. Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары белән билгеләнгән вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны алмаштыру өчен | Кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затлары, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча | Ярты елга бер мәртәбә | Муниципаль хезмәткә беренче тапкыр керешүче һәм укулар узган хезмәткәрләрнең саны муниципаль хезмәткә беренче тапкыр керешүчеләрнең | | | | | 90% | 90% | 90% | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| муниципаль хезмәткә беренче мәртәбә кергән муниципаль хезмәткәрләрне коррупциягә каршы тору өлкәсендәге белем бирү программалары буенча ел саен укыту | эш өчен җаваплы кешеләр (килештерү буенча) | | гомуми саныннан (90% тан ким түгел) | | | | | | | | | | | | | |
| 11.4. Коррупциягә каршы торуда катнашу вазыйфаи бурычларына кергән муниципаль хезмәткәрләрнең ел саен квалификацияләрен күтәрү | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килештерү буенча), кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затлары, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы кешеләр (килештерү буенча) | Ярты елга бер мәртәбә | Коррупциягә каршы торуда катнашу вазыйфаи бурычларына кергән квалификацияләрен күтәрүне узган хезмәткәрләрнең саны (50%тан ким түгел) | | | | | 50% | 50% | 50% | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 11.5. Кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затлары, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы кешеләр тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфаларын алмаштыручы затларның, муниципаль районда эшләүче җәмәгатьчелек советлары әгъзаларының коррупциягә каршы тору һәм аларны бозган өчен җәзаның котылгысыз булуы турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләре хакында хәбәрдарлыгын арттыру буенча чаралар күрү | Кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затлары, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы кешеләр (килештерү буенча), коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килештерү буенча) | Ярты елга бер мәртәбә | Үткәрелгән индивидуаль чараларның саны муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль районда эшләүче җәмәгатьчелек советлары әгъзалары саныннан (50%тан ким түгел) | | | | | 50% | 50% | 50% | - | - | - | - | - | - |
| 11.6. Карамактагы оешмалар уставларының, | Җирле үзидарә органнарының, карамактагы | 2018 ел | Уставларының, җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре | | | | | 100% | | | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| карамактагы оешмаларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт шартнамәләренең мәнфәгатьләр низагын булдырмау һәм көйләү мәсьәләләрен җайга салучы нормалар өлешенә үзгәрешләр кертү<br>. | оешмаларның кадрлар хезмәте (һәр икесе дә килештерү буенча), коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килештерү буенча) | | белән төзелгән хезмәт шартнамәләренең мәнфәгатьләр низагын булдырмау һәм көйләү мәсьәләләрен җайга салучы нормаларына үзгәрешләр кертелгән карамактагы оешмалар саны | | | | | | | | | | | | | |
| 11.7. Карамактагы оешмаларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре тарафыннан карамактагы оешмалар уставлары һәм хезмәт шартнамәләренең мәнфәгатьләр низагын булдырмый калу һәм җайга салуга кагылышлы таләпләрен үтәү өчен контрольне гамәлгә ашыру, аны булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча, шул исәптән мәнфәгатьләр | Җирле үзидарә органнарының, карамактагы оешмаларның кадрлар хезмәте (һәр икесе дә килештерү буенча), коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килештерү буенча) | Ярты елга бер мәртәбә | Карамактагы оешмаларның уздырылган тикшерүләре саны аларның гомуми саныннан;<br>Ачылган / көйләнгән мәнфәгатьләр низагы фактларының саны;<br>Мәнфәгатьләр низагын булдырмый калу һәм /яки аны җайга салу буенча чаралар күрмәгән өчен җаваплылыкка | | | | | 100% | 100% | 100% | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| низагын булдырмый калу һәм җайга салу турындагы таләпләр тарала торган затларны да әлеге таләпләрне үтәмәгән очракта җаваплылыкка тартып чаралар күрү | | | тартылган җитәкчеләр һәм /яки хезмәткәрләр саны | | | | | | | | | | | | | |
| 11.8. Сатып алуда катнашучы һәм заказ бирүче арасында мәнфәгатьләр низагы килеп чыгуны, шулай ук башка хокук бозуларны булдырмый калу максатларында карамактагы оешмаларның 2011 елның 18 июлендәге “Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында”гы 223-ФЗ номерлы Федераль законга туры китереп гамәлгә ашырылучы сатып алуларына анализ үткәрү | Муниципаль районның муниципаль унитар предприятиеләре, муниципаль районның Контроль-хисап палатасы (килештерү буенча), ТР Балык Бистәсе муниципаль районының “Муниципаль заказ хезмәте” МКУ се | Ярты елга бер мәртәбә | Үткәрелгән тикшерүләр саны/ачылган хокук бозулар саны/ шул исәптән мәнфәгатьләр низагы белән бәйле булганнары (50 % тан ким түгел) | | | | | 50% | 50% | 50% | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 11.9. Контрактның башлангыч (минималь) бәясе 5 млн. сумнан артык булган очракта муниципаль ихтыяж ларны тәэмин итү өчен товарлар, эш, хезмәт күрсәтүләр сатып алу буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары үткәрү | МР ның Җәмәгатьчелек Советы (килештерү буенча), ТР Балык Бистәсе муниципаль районының “Муниципаль заказ хезмәте” МКУ се, муниципаль заказ бирүчеләр (килештерү буенча) | Ярты елга бер мәртәбә | Үткәрелгән җәмәгатьчелек фикер алышулары саны контрактларының башлангыч (минималь) бәясе 5 млн. сумнан артык булган гамәлгә ашырылган сатып алулар саныннан (мондый сатып алуларның 50% ыннан ким түгел) | | | | | 50% | 50% | 50% | - | - | - | - | - | - |
| 11.10. Муниципаль районда коррупциягә каршы, шул исәптән коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе, кадрлар хезмәтенең вазыйфаи затлары, коррупцияне һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы кешеләр катнашында | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килештерү буенча) | Квартал саен | Коррупциягә каршы эшчәнлектә хәбәрдарлыкны тәэмин итү, гражданнарның мәгълүмат алуга хокукларын тормышка ашыру, шул исәптән коррупциягә каршы тору өлкәсендә күрелә торган чаралар турында мәгълүмат алуга. | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| үткәрелгән эшнең нәтиҗәләре турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү буенча эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген күтәрү, | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 11.11. Коррупциягә каршы тору муниципаль программасын тормышка ашыру турында хисаплар буенча (муниципаль районда эш алып баручы экспертлар оешмасын, җәмәгатьчелек советлары әгъзаларын җәлеп итеп) җәмәгатьчелек фикер алышулары үткәрү | МР ның Җәмәгатьчелек Советы (килештерү буенча), коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килештерү буенча) | Ел саен | Коррупциягә каршы эшчәнлектә хәбәрдарлыкны тәэмин итү, гражданнарның мәгълүмат алуга хокукларын тормышка ашыру, шул исәптән коррупциягә каршы тору өлкәсендә күрелә торган чаралар турында мәгълүмат алуга. | | | | | | | | - | - | - | - | - | - |
| 11.12.Коррупциягә каршы тору муниципаль программасын тормышка ашыру турында хисапны районның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми | Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килештерү буенча) | Ел саен 1 февральгә кадәр | | | | | | | | | - | - | - | - | - | -» |

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| сайтында “Коррупциягә каршы тору “ бүлегендә урнаштыру | | | | | | | | | | | | | | | | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Л. Исланов